РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 26

2025 елның 12 декабре

# Түбән Кама муниципаль районы Советының хезмәт хакы турында кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы таралмаган бюджет даирәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру һәм «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 ноябрендәге 996 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 48 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1 2 пунктта «15 389 саннарын 16 928 саннарына” алмаштырырга;
1.2. 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);
1.3. 4 нче кушымтаның 3 пунктындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Күрсәтелгән вакыт аралыгында муниципаль вазыйфага билгеләнү көненә кадәр Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарында өзлексез хезмәт эшчәнлеге кертелә.»;

2. 16 нчы кушымтаның 3 пунктындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Күрсәтелгән вакыт аралыгында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнү көненә кадәр Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарында өзлексез хезмәт эшчәнлеге кертелә.»;

3. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган

Түбән Кама муниципаль районының бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 49 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. 1 пунктның дүртенче абзацында «15 389 саннарын 16 928 саннарына» алмаштырырга;

3.2. 3 пунктның 5 пунктчасындагы икенче абзацының икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Күрсәтелгән вакыт аралыгында хезмәткәрне эшкә алу көненә кадәр Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарында өзлексез хезмәт эшчәнлеге кертелә.»;

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә. Әлеге карарның 1.3, 1.4 һәм 2.2 пунктларының гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

5.Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

Р.И. Беляев

Түбән Кама муниципаль районы Советының
2025 елның 12 декабрендәге
26 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Советының
2021 елның 1 сентябрендәге
48 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга
айлык акчалата түләү күләмнәре

| № п/п | Хезмәт өчен түләү төркеме (муниципаль берәмлек халкының санына карап) | 3 төркем |
|---|---|---|
| | | о 250 дән 500 меңгә кадәр кеше (сум.) |
| 1 | Муниципаль берәмлек Башлыгы | 51 476 |
| 2 | Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 46 327 |
| 3 | Депутат | 25 151 |
| 4 | Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 21 371 |
| 5 | Контроль-хисап палатасы рәисе | 46 327 |
| 6 | Контроль-хисап палатасы Рәисе урынбасары | 41 641 |
| 7 | Контроль-хисап палатасы аудиторы | 34 869 |

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары А.В. Умников